**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

## Татарстан Республикасы
## Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
## КАРАРЫ

**2016 елның «11» августыннан** **№ 17-71**

### Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2016-2021 елларга социаль-икътисадый үсеш стратегиясен беренче чиратта гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 23 статьясы, Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2016 елның 11 августындагы 17-70 номерлы карары белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2016-2021 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенберенче чиратта гамәлгә ашыру чаралары планын кушымта нигезендә расларга.
2. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына, район предприятиеләренә һәм оешмаларына 2016-2021 елларга Татарстан Республикасы

Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын үтәү чараларын күрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (Pravo.tatarstan.ru) һәм ИНТЕРНЕТ мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**

# 2016-2021 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенберенче чиратта гамәлгә ашыру чаралары планы

| Максат/бурыч | Чараның эчтәлеге | Үтәү сроклары | Башкаручы | Көтелгән нәтиҗәләр | Муниципаль программаларга кертү |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| 1 нче максат Кеше капиталы | | | | | |
| Халык динамикасы: туучылар саны югары һәм халыкның тотрыклы миграция агымы. | Балалы гаиләләргә матди ярдәм күрсәтүнең адреслылыгын арттыру, шул исәптән:<br>- өч яшькә кадәрге балаларны бушлай махсус сөт продуктлары белән тәэмин итү | 2016-2021 | Яңа Чишмә МР БК, ТР Хезмәт министрлыгы, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы | Өч яшькә кадәрге балаларны бушлай махсус сөт продуктлары белән 99,86 процентган да ким булмаган күләмдә тәэмин итү | |
| | Гаиләләрнең тормыш циклының төп этаплары буенча эффектив чаралар бүлү, шул исәптән:<br>- халыкның репродуктив сәламәтлеген яхшырту буенча чараларны гамәлгә ашыру, репродуктив технологияләрне куллану | 2016-2021 | | Экстракорпораль аталану аша туган балалар санын арттыру | |
| үлүчеләр санын киметү һәм гомер озынлыгын арттыру: | Булдырмый калып була торган иртә үлем очракларының кимәтү, шул исәптән:<br>- халыкның аерым яшь төркемнәренә диспансеризация үткәрү;<br>- үлем очракларының төп сәбәпләрен иртә диагностикалау; Татарстан Республикасында онкология хезмәте күрсәтүне модернизацияләү<br>- Татарстан Республикасы Бердәм | 2016-2021 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты ТР министрлыклары һәм ведомстволары белән берлектә | Гомуми үлүчеләр санын 2030 елда 1000 кешегә 14,1 очракка кадәр кимәтү. Көч кулланып үтерелгән үлемнәр санын кимәтү | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | дәүләт мәгълүмат системасы базасында «112» бердәм номеры буенча экстрен-оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасын үстерү һәм аңа ярдәм итү | | | | |
| | Үз-үзеңне саклау тәртибенең һәм сәламәт, актив гомер озынлыгының үсеше, шул исәптән:<br>- авыруларны профилактикалау | 2016-2021 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты ТР , Яңа Чишмә МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Гомуми үлүчеләр санын 2030 елда 1000 кешегә 14,1 очракка кадәр киметү. | |
| Сәламәтлекне саклау һәм озак яшәүне озайту - төп приоритетлар | Гражданнарның сәламәтлеген саклауга юнәлдерелгән ресурсларның барлык чыганакларын (барлык дәрәҗәдәге бюджетлар, предприятиеләрдә хезмәткәрләрне савыктыруга капитал салу, хәйрия, халыкның шәхси түләүләре, ведомстволар куәтләре, регионара һәм халыкара элемтәләрдән файдалану мөмкинлекләре h.б.) инвестицияләү һәм алардан файдалану; | 2016-2021 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты ТР министрлыклары һәм ведомстволары белән берлектә | Сәламәтлек саклауга җибәрелә торган ресурсларның барлык чыганакларын ел саен арттыру | |
| | Йөкләмәләр күләмен халыкның төрле категорияләренең дифференциацияләнгән ихтыяҗларын исәпкә алып, шул исәптән:<br>- халыкның төрле төркемнәре буенча медицина хезмәт күрсәтү төрләрен | 2016-2021 | ТР Сәламәтлекне саклау министрлыгы (килешү буенча) | 2021 елга халыкның көтелгән гомер озынлыгын 70,71 елга кадәр арттыру | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | дифференциацияләү;<br>- куәтле лаборатор һәм диагностик базасы булган районара үзәкләр булдыру | | | | |
| | Ведомствоара һәм территориальара хезмәттәшлек мөмкинлекләрен һәм ресурсларны файдалануның мөмкин бул-ган альтернатив юнәлешләре нәтиҗәсен анализлау нигезендә оешмаларның һәм гражданнарның шәхси инициативаларын ак-тивлаштыруны исәпкә алып, ресурслардан файдалануны план-лаштыру;<br><br>- дәүләт-хосусый партнерлык кысаларында аларга тапшыру өчен потенциаль инвесторлар белән, шул исәптән концессия шартнамәсе буенча, файдаланылмый торган биналар һәм медицина учреждениеләренең файдаланылмый торган биналары белән, халыкның ихтыяҗларын һәм дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнашуын исәпкә алып, медицина ярдәменең таләп ителгән төрләрен күрсәтүне оештыру өчен үзара хезмәттәшлек | 2016-2021 | ТР Сәламәтлекне саклау министрлыгы (килешү буенча) | 2021 елга халыкның көтелгән гомер озынлыгын 70,71 елга кадәр арттыру | |
| | Телемедицина технологияләрен һәм заманча коммуни-кация чараларын үстерү исәбенә пациентның сәламәтлек саклау системасы белән | 2016-2021 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты ТР министрлыклары | 2021 елга халыкның көтелгән гомер озынлыгын 70,71 елга кадәр арттыру | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | үзара хезмәттәшлек итү модельләрен арттыру;<br>- авыруның һәм клиниканың дистанцион үзара тәэсир итешүе мобиль җайланмаларны һәм организм төп параметрларын мониторинглау, кешенең сәламәт яшәү рәвешен тәэмин итү өчен үткәргечсез технологияләр куллану;<br>- медицина ярдәмен иң минималь кирәкле диагностик процедуралар җыелмасы булган гомумтабиб практикаларының челтәрен үстерү ярдәмендә адымнар белән файдалана алу мөмкинлегендә;<br>- «мобиль, диагностик комплекслар» белән беренчел звено табибларын һәм фельдшерларын тәэмин итү, алар авыруның ятагы янында тикшеренүләр үткәрергә һәм белгечләргә җибәрергә мөмкинлек бирә. | | һәм ведомстволары белән берлектә | | |
| | Медицина персоналы хезмәтенә пациентларның канәгатьләнүенә йөз тоткан түләүнең нәтиҗәле мотивацион системаларын кертү;<br>- стимуллаштыру (бүләкләү) системасында исәпкә алына торган медицина хезмәткәрләренең төп категорияләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең һәм күрсәткечләрен актуальләштерү;<br>- Татарстан Республикасы | 2016-2021 | ТР Сәламәтлекне саклау министрлыгы (килешү буенча) | 2021 елга халыкның көтелгән гомер озынлыгын 70,71 елга кадәр арттыру<br>Аккредитацияләнгән белгечләр өлешенең 2021 елга 100 процентка кадәр үсеше | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәткәрләре медицина хезмәткәрләре ассоциациясе катнашында белгечләрне аккредитацияләүне оештыру | | | | |
| | Сәламәтлекне саклауның төрле рәвешләрен үстерү индивидуаль механизмны үзенең биологик потенциалын саклап калу, шул исәптән ирекле медицина иминләштерүен үстерү өчен пациентның җаваплылыгын кертү | 2016-2021 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты ТР министрлыклары һәм ведомстволары белән берлектә | Гражданнарның үз сәламәтлеген саклап калу өчен җаваплылыгын арттыру | |
| Мәдәни тормышта катнашуга, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләреннән файдалануга гражданнарның конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар тудыру | Мәдәни билгеләнештәге объектлар төзү һәм торышы канәгатьләнерлек булмаган һәм мәдәни эшчәнлекне гамәлгә ашыру шартларына заманча таләпләргә җавап бирми торган учреждениеләр биналарын ремонтлау | 2016 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, мәдәният учреждениеләре | Канәгатьләнерлек хәлдә булган учреждениеләр санын арттыру | 2014-2016 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәдәният һәм сәнгать үсеше программасы |
| Гражданнарның район китапханә фондларының мәдәни һәм мәгълүмати ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү | Мәдәният учреждениеләре челтәрен саклау һәм ныгыту | 2016-2021 | ТР Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге | Мәдәни тормышның сыйфатын һәм төрлелеген тәэмин итү | 2014-2016 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәдәният һәм сәнгать үсеше программасы |
| | Муниципаль китапханәләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын һәм төрлелеген арттыру | 2016-2021 | Яңа Чишмә муниципаль районының «Үзәкләштерелгән клублар | Шәһәр һәм район халкының мәгълүмати, танып белү һәм эстетик үтенечләрен тулысынча канәгатьләндерү | 2014-2016 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәдәният |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе | | һәм сәнгать үсеше программасы |
| | Музей фондлары әйберләрен саклау һәм арттыру, музей процессларын модернизацияләү | 2016-2021 | «Яңа Чишмә туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе һәм Зирекле авылының «Халык иҗаты һәм көнкүреше музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе | Музейларның фәнни-тикшеренү, фәнни-фонд эшчәнлеген камилләштерү | 2014-2016 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәдәният һәм сәнгать үсеше программасы |
| Эстетик белем бирү системасын үстерү, яшь талантларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү | Сәнгать-эстетик юнәлештәге башлангыч белем бирүне саклау һәм үстерү | 2016-2021 | Яңа Чишмә муниципаль районының өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләре | Сәнгать-эстетик юнәлештәге белем бирү учреждениеләрендә укучылар контингентын саклау | 2014-2016 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәдәният һәм сәнгать үсеше программасы |
| | Сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклауга, аларның иҗади үсеше өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән конкурс-фестиваль чаралары уздыру | 2016-2021 | | Гомуми балалар саныннан иҗади чараларда катнашырга җәлеп ителгән балаларның өлешен арттыру | |
| Күчмә мәдәни- | Мәдәният өлкәсендә стационар | 2016-2021 | «Яңа Чишмә | Мәдәният | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| мәгълүмат комплекслары эшчәнлеген тәэмин итү | булмаган хезмәтләрдә спектрны киңәйтү: автоклублар, киновидеопредвижкалар, урамда кино күрсәтү, китапханә пунктлары | | муниципаль районы үзәкләштерелгән район клуб системасы» муниципаль бюджет учреждениесе, «Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе | учреждениеләре хезмәтләре белән халыкны колачлау өлешен арттыру | |
| Белем бирү оешмаларында фәнни-белем бирү һәм иҗади мохитне үстерү буенча чараларны гамәлгә ашыру, балаларга өстәмә белем бирү системасын үстерү | Балаларга өстәмә белем һәм тәрбия бирү эчтәлеген һәм технологияләрен яңарту | 2017-2021 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, Яңа Чишмә МР Башкарма комитетының мәгариф бүлеге. | Барлык өстәмә белем бирү учреждениеләреннең үсеш программаларын булдыру | |
| | Укучыларны актив социаль практикага җәлеп итү механизмнарын булдыру | ел саен | | Мәгариф хезмәтләрен сайлау өчен муниципаль мәгълүмат базасын булдыру. Индивидуаль нәтиҗәләр мониторинг системасын булдыру | |
| | Талантлы укучыларның иҗади һәм интеллектуаль сәләтләрен ачыклау һәм үстерү өчен кирәкле шартлар | 2017-2021 | | Фәннәр буенча олимпиадаларында һәм интеллектуаль | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | тудыру | | | конкурсларда катнашучылар санын 50% ка җиткерү | |
| | Авыр тормыш хәлендә булган балаларны нәтиҗәле социализацияләүне тәэмин итү | ел саен | | Авыр тормыш хәлендә булган балаларның 100% ын- өстәмә белем бирү системасына җәлеп итү | |
| Яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә наркотиклар куллануга тискәре караш һәм сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация формалаштыру. | Профилактик яшьләр акцияләре, түгәрәк өстәлләр, очрашулар, семинарлар уздыру | ел саен | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Сәламәт яшәү рәвешенә йөз тоткан балалар һәм яшьләр санын арттыру | 2014-2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау программасы |
| | «Спорт наркотикларга каршы» сәламәтлек акциясе | 2016 | Яңа Чишмә муниципаль районының ирекләләр хәрәкәтен үстерүнең координацион үзәге | Сәламәт, спортлы яшәү рәвешен пропагандалау, психоактив матдәләр куллануны профилактикалау һәм яшьләр арасында төрле спорт төрләрен популярлаштыру | |
| | | 2016 | | Ирекләләр арасында «Тигезгә — тигез» принцибы буенча социаль театр технологиясе буенча белем бирү дәресләре һәм тренинглар үткәрү. Наркотикларга каршы массакүләм профилактик чаралар | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | үткәрү | |
| Сәләтле балаларны ачыклау, аларга ярдәм итү, укыту, тәрбияләү һәм үстерү | «Алтын каләм» район фестивале | 2016 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Яңа Чишмә МРның иң актив һәм талантлы укучыларын ачыклау, укуга һәм дәрестән тыш актив эшчәнлеккә мотивация булдыру | 2014-2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау программасы |
| | КВН уеннары | | | Яңа Чишмә МР яшьләренең иҗади потенциалын гамәлгә ашыру һәм алга таба да ярдәм итү | |
| | «ВАТАН» халык иҗаты фестивале | | | Яңа Чишмә МР яшьләренең иҗади потенциалын гамәлгә ашыру һәм алга таба да ярдәм итү | |
| Патриотик тәрбия системасын үстерү һәм модернизацияләү, балаларда һәм яшьләрдә гражданлык үзенчәлеген формалаштыру | Хәрби хезмәткә алынучылар (призывник) көне | ел саен | Яңа Чишмә муниципаль районының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Балаларның һәм яшьләрнең әхлакый потенциалын арттыру, гражданлык һәм ватанпәрвәрлеген үстерү | 2016 - 2020 елларга «Яңа Чишмә муниципаль районы балаларын һәм яшьләрен патриотик тәрбияләү» муниципаль максатчан программасы |
| | «Георгий тасмасы» акциясе | | «Яңа Чишмә муниципаль районы узәкләштерелгән клуб системасы» МБМУ, Яңа Чишмә муниципаль районы узәкләштерелгән | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | китапханә системасы» МБМУ, иҗтимагый оешмалар, волонтерлар | | |
| | «Үлемсез полк» шәһәр акциясе | | «Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» МБМУ, Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБМУ, иҗтимагый оешмалар, волонтерлар | | |
| | «Җиңү өчен бабайга рәхмәт» иреклеләр акциясе - Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераннарына, өлкән яшьтәгеләргә адреслы ярдәм | | «Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» МБМУ, Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханә | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | системасы» МБМУ, иҗтимагый оешмалар, волонтерлар | | |
| Спорт-массакүләм хәрәкәтне үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру, халыкны даими рәвештә физик культура белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау | Бөек Ватан сугышында Җиңүгә багышланган җиңел атлетика эстафетасы | 2016 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | Яңа Чишмә МР халкының актив ял итүе, начар гадәтләргә тартылуны спорт белән шөгыльләнү, сәламәт дәрт, гадел көрәштә җиңү теләгенә алыштыру | «2016-2020 елларга Яңа Чишмә МРда физик культураны үстерү» муниципаль программасы |
| | Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы призына чаңгы марафоны | | | | |
| | «Милләтләр кроссы» Бөтенроссия йөгерү көне кысаларында массакүләм стартлар | | | | |
| | «Россия чаңгы юлы» Бөтенроссия чаңгы ярышы кысаларында массакүләм стартлар | | | | |
| | Кышкы спорт сезонын ачу һәм ябу | | | | |
| | Спорт төрләре буенча район беренчелекләре һәм кубоклары | | | | |
| Халыкны эш белән тәэмин итүнең актив формалары буенча эшне оештыру | Эшсез гражданнар өчен түләүле иҗтимагый эшләр оештыру | ел саен | «Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | Эшсез гражданнарны вакытлыча эш белән тәэмин итү | |
| | 14-18 яшьлек гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру | | | Балигъ булмаган гражданнарның укудан буш вакытларында вакытлыча мәшгульлеген тәэмин итү | |
| | Эшсез гражданнарның мәшгульлегенә ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү | | | Гражданнарның үзмәшгульлеген оештыру | |
| | Эшсез гражданнарга һөнәри белем бирүне оештыру | | | Яңа һөнәр буенча эшсез гражданнарны эшкә | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | урнаштыру | |
| Эш эзләүдә кыенлыклар кичергән гражданнарны эшкә урнаштыру эшен оештыру | Урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру (Беренче эш урыны). | ел саен | «Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | Урта һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан эшсез гражданнарны эшкә урнаштыру | |
| | Беренче тапкыр эш эзләүче гомуми белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру (Яшьләр сәясәте). | | | Гомуми белем бирү оешмаларын һәм югары һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан эшсез гражданнарны эшкә урнаштыру | |
| Мөмкинлекләре чикләнгән гражданнарны, күпбалалы ата-аналарны эшкә урнаштыру эшен оештыру | Күп балалы эшсез ата-аналарны һәм инвалид балалар тәрбияләүче эшсез ата-аналарны алар өчен булдырылган(җиһазландырылган) эш урыннарына эшкә урнаштыруда ярдәм оештыру | ел саен | «Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | Эшсез гражданнар арасыннан инвалид балалар тәрбияләүче күп балалы ата-аналарны эшкә урнаштыру | |
| | Эшсез инвалидларны җиһазландырылган (җиһазландырылган) эш урыннарына эшкә урнаштыруда ярдәм оештыру | | | Эшсез гражданнар арасыннан инвалидларны эшкә урнаштыру | |
| 2 нче максат Пространство, реаль капитал. | | | | | |
| Фонд җиһазларын арттыру | Җиһазларны модернизацияләү, сөт продуктларын, ит продуктларын төргәкләү линиясен сатып алу һәм эшләтеп җибәрү | 2017-2020 | «ПРОСТО МОЛОКО» ИК» ҖЧҖ филиалы» Яңа Чишмә заводы», «Белоглазова | Техниканы йөкләү эффективлыгын күтәрү һәм оптимальләштерү, яңа төр продуктлар җитештерү | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Е.Е. КФХ» ЖЧҖ «Карат» СПК | | |
| | Җиһазларны модернизацияләү, төзелеш тармагы ихтыяҗлары өчен махсус техника сатып алу | 2016-2020 | Төзелеш тармагын оештыру | Җиһазларны йөкләү эффективлыгын арттыру һәм оптимальләштерү, яңа технологияләр куллану | |
| | Икмәк һәм икмәк-күмәч әйберләре җитештерү өчен технологик җиһазларны модернизацияләү | 2016-2020 | Икмәк пешерү тармагы предприятиеләре | Техниканы йөкләү эффективлыгын күтәрү һәм оптимальләштерү, яңа төр продуктлар җитештерү | |
| | Авыл хуҗалыгы тармагында техника һәм технологик җиһазлар сатып алу | 2016-2020 | Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләр е | Җиһазларны йөкләү эффективлыгын арттыру һәм оптимальләштерү, яңа технологияләр куллану | |
| Мөгезле эре терлекләрнең баш санын саклау өчен уңайлы мохит булдыру | 100 һәм 200 башка исәпләнгән сыер абзарларын капиталь ремонтлау | 2016-2020 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре | Хайваннарны асрау шартларын яхшырту | |
| | Силос-сенаж траншеялары төзү | 2016-2020 | КФХ башлыклары | Хайваннарны тукландыруны яхшырту | |
| Терлекләрнең генофондын яхшырту | - бруцеллез, туберкулез, себер язвасы һәм элек район территориясендә теркәлмәгән авырулар барлыкка килүгә юл куймау | 2016-2020 | «Яңа Чишмә район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | Терлекләрнең баш санын савыктыру һәм авыруларга юл куймау, экологик чиста продукция | |
| | - антимастит программасы (антибиотиксыз экологик чиста сөт) | | | | |
| | - мөгезле эре терлекләрнең баш санын лейкоздан арындыру | | | | |
| Уҗым культуралары | Мелиорация эшләре буенча | 2016-2020 | ТР авыл | Бәрәңгенең, кузаклы | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| продукциясе җитештерү үсешен стимуллаштыру | чараларны финанслау | | хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (килешү буенча) | культураларның, күпьеллык үләннәрнең уңышын арттыру | |
| Икътисадны үстерүгә ярдәм итүче сыйфатлы юл челтәрен булдыру | Юл өслеген яхшырту, булган юл челтәрен ремонтлау | ел саен | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, подрядчы оешмалар | Юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү, юл челтәрен эксплуатацияләү срогын арттыру | ТР Яңа Чишмә районында М-800 вак таш-ком катнашмасыннан өслекле юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү;<br>ТР район үзәкләренең һәм шәһәрләренең асфальт җәелгән юл-урам челтәрен ремонтлау;<br>Яңа Чишмә муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы (юл фонды)<br>ТР район үзәкләренең һәм шәһәрләренең асфальт җәелгән юл-урам челтәрен ремонтлау;<br>Яңа Чишмә муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы (юл фонды) |
| Юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар санын киметү | Җәяүлеләр өчен коймаларны реконструкцияләү һәм төзү | ел саен | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, подрядчы оешмалар | Социаль куркынычларны киметү; транспорт куркынычын киметү | «2016-2018 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасы |
| | Турыдан-туры мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә һәм балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренә җәяүлеләр өчен җайга салынмый юл кичүләре төзү, реконструкцияләү, техник яктан яңадан җиһазландыру | | | | |
| | Юл билгеләрен урнаштыру, шул исәптән торак пунктларда да | | | | |
| Торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү сыйфаты стандартларын тәэмин итү | Җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү системасын модернизацияләү. Ташландык суларны агызу, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү | 2016-2017 | Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- подрядчы оешмалар | Җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу системасын үстерү һәм модернизацияләү, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү | 2014-2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районының коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерүнең һәм торак фондын модернизацияләүнең муниципаль программасы» |
| Яңа белем бирү стандартларын тормышка ашыру шартларын тәэмин итүче инфраструктура | Мәгариф оешмаларында ФГОС таләпләренә туры килә торган заманча матди-техник шартлар булдыру, мәктәпкәчә, башлангыч, төп һәм урта гомуми белем | ел саен | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, мәгариф бүлеге | Барлык мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә һәм гомуми белем бирү оешмаларында ФГОС | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| булдыру | дәрәҗәләрендә, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен дә | | | таләпләренә туры килә торган шартлар тудыру | |
| 3 нче максат Базарлар | | | | | |
| Яңа Чишмә муниципаль районы полимерларын эшкәртү буенча 2 номерлы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерү | Полимерлар эшкәртү буенча 2 номерлы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында заманча сәнәгать җитештерүләре урнаштыру | 2016-2020 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, «Яңа Чишмә муниципаль районы ИК» МУП ПП МУ резидентлары | Кече һәм урта бизнесны үстерү, аның структурасын яхшырту | 2014-2016 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү буенча муниципаль программа |
| Авыл хуҗалыгы производствосы өлкәсендә хуҗалык итүнең кече формаларын үстерүне стимуллаштыру | КФХлар, ИП, гаилә фермалары төзүдә, шул исәптән җир кишәрлекләрен һәм биналарны рәсмиләштергәндә ярдәм күрсәтү юлы белән авылда эшкуарлыкны үстерүгә булышу | 2016-2020 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, ЦЗН (килешү буенча), УСХиП (килешү буенча) | | 2015-2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкны үстерүнең муниципаль программасы |
| 4 нче максат Институтлар | | | | | |
| Дәүләт-шәхси партнерлык механизмнарын үстерү | Яңа Чишмә муниципаль районы полимерларын эшкәртү буенча 2 номерлы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерү | 2016-2020 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, «Яңа Чишмә муниципаль районы ИК» МУП ПП МУ резидентлары | Яңа Чишмә муниципаль районының кече һәм урта бизнесын үстерү | |
| Салым базасын | Муниципаль милек, җир | 2016-2020 | ПИЗО, ФБП | Салым һәм салым | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| арттыру | кишәрлекләре, вариссыз калган һәм хуҗасыз мөлкәткә инвентаризация үткәрү | | | булмаган керемнәрнең өлешен 36%ка кадәр арттыру | |
| | Муниципаль мөлкәтне концессиягә, арендага бирү, гарантияләр бирү өчен кредит оешмаларына залогка тапшыру | 2016-2020 | ПИЗО, ФБП | | |
| 5 нче максат Инновацияләр һәм мәгълүмат | | | | | |
| Гомуми белем бирүнең заманча механизмнарын һәм технологияләрен үстерү | Мәктәп инициативаларына һәм челтәр проектларына конкурс аша яңа технологияләр куллану һәм укыту һәм тәрбияләү өчен инновацион программалар тормышка ашыручы мәктәпләр челтәрен булдыру | 2016-2021 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, Яңа Чишмә МР Башкарма комитетының мәгариф бүлеге. | Инновацион программаларны гамәлгә ашыручы мәктәпләр санын 35% тан 50%ка кадәр арттыру | |
| | ФГОС нигезендә укыту технологияләрен һәм эчтәлеген, шул исәптән инклюзив мәгариф системасында да, модернизацияләү | 2017-2021 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, Яңа Чишмә МР Башкарма комитетының мәгариф бүлеге. | Югары белем бирү нәтиҗәләренә нигезләнеп, белем бирүнең технологияләрен уку эчтәлеген яңарту. Чыгарылыш сыйныф укучыларын киләчәктә югары технологияле икътисадта белем алуга һәм эшчәнлеккә әзерләү. Барлык инвалид балаларга гомуми белем бирү программаларын үзләштерү мөмкинлеген бирү | |
| | Инклюзивны да кертеп, гомуми | ел саен | Яңа Чишмә МР | Мәгариф өлкәсендә | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | белем бирү һәм балаларга өстәмә белем бирү педагогик һәм җитәкче кадрларының һөнәри дәрәҗәсен күтәрү | | Башкарма комитеты, Яңа Чишмә МР Башкарма комитетының мәгариф бүлеге. | югары квалификацияле хезмәткәрләр санының чагыштырма зурлыгын 70% тан 85% ка кадәр арттыру. 30 яшькә кадәр укытучыларның санын 7% тан 12% ка кадәр арттыру | |
| | Мәгарифкә ата-аналарны җәлеп итү, мәгариф белән идарә итүдә җәмәгатьчелекне катнаштыру механизмнарын үстерү | ел саен | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, Яңа Чишмә МР Башкарма комитетының мәгариф бүлеге. | Барлык мәгариф учреждениеләрендә дә ата-аналар советы булдыру, дәүләт йомгаклау аттестациясендә җәмәгать күзәтүчеләрен катнаштыруны оештыру. Мәгариф оешмалары эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын тәэмин итү | |
| Белем бирү сыйфатын һәм белем бирү нәтиҗәләрен бәяләүдә ихтыяҗ булган системаны формалаштыру | Гомуми белем бирүнең сыйфатын бәяләүнең муниципаль системасын үстерү | 2017-2018 | Яңа Чишмә МР Башкарма комитеты, Яңа Чишмә МР Башкарма комитетының мәгариф бүлеге. | Балаларга мәктәпкәчә, гомуми һәм өстәмә белем бирү баскычларында белем бирү сыйфатын бәяләү буенча экспертларның һөнәри-педагогик берләшмәсен булдыру | |
| | Мәгариф системасын мониторинглау өлкәсендә инновацияләргә ярдәм итү | 2017-2021 | | Барлык гомуми белем баскычларында да заманча уку | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | казанышларын мониторинглау системасын булдыру | |
| 6 нчы максат Табигый ресурслар | | | | | |
| Туфракның уңдырышлылыгын саклау һәм торгызу өчен шартлар тудыру, авыл хуҗалыгы җирләрен мелиорацияләүне үстерү | Үсемлекчелеккә тотрыклы югары ихтыяҗы булган культуралар кертү | 2016-2020 | ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (килешү буенча) | Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең керемнәре арттыру | |
| 7 нче максат Финанс капиталы | | | | | |
| Татарстан Республикасында Яңа Чишмә муниципаль районының ВТБ өлешен арттыру | | 2016-2020 | Милек рәвешенә карамастан, Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы хуҗалык итүче субъектлар | Тулаем территориаль продукт - 14451 млн. сум тәшкил итә | |
| Гомуми рРеспублика инвестицияләрендә Яңа Чишмә муниципаль районының өлешен арттыру | Яңа Чишмә муниципаль районы полимерларын эшкәртү буенча 2 номерлы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерү | 2016-2020 | Эшкәртүдә | Яңа Чишмә муниципаль районының инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру, уртача еллык инвестицияләр күләмен арттыру | |